**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6156**
**07.11.2022**

Башкарма комитетның 2022 елның 11 февралендәге 623 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 20.10.2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 11 февралендәге 623 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.3. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (алга таба – Оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:

судьяларның балалары;

прокурорларның һәм Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән категориядәге гражданнарның балалары;

террорчылык оешмаларын ачыклау һәм аларның эшчәнлеген булдырмау буенча махсус көчләрнең һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр үткәрү буенча берләштерелгән гаскәрләр (көчләр) төркеме төркемнәренең һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булып калган хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары;

Дагстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең балалары;

Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узу чорында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары.

Оешмага беренче чиратта урнашу хокукына ия:

инвалид балалар һәм ата-анасының берсе инвалид булган балалар;

күп балалы гаилә балалары;

полиция хезмәткәренең балалары, шул исәптән хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) полиция хезмәткәренең балалары; полициядә хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә авыру нәтиҗәсендә үлгән полиция хезмәткәренең балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгән Россия Федерациясе гражданының балалары; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә яисә полициядә хезмәт итү чорында алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган авыру нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел эчендә үлгән Россия Федерациясе гражданының балалары; Россия Федерациясе гражданы, полиция хезмәткәре тәрбиясендә булучы (булган) балалар;

хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтнең федераль янгынга каршы хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче, шул исәптән хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән); хезмәт итү чорында алынган авыру нәтиҗәсендә үлгән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган һәм алга таба хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә полиция хезмәтеннән азат ителгән; хезмәт вазыйфаларын үтәүгә

бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлегенә башка зыян килү нәтиҗәсендә яисә хезмәт итү чорында алга таба хезмәт итү мөмкинлеге бирми торган авыру нәтиҗәсендә хезмәтеннән азат ителгәннән соң бер ел эчендә үлгән Россия Федерациясе гражданының балалары; Россия Федерациясе гражданы, хезмәткәре тәрбиясендә булучы (булган) балалар.

Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар, мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча укуга, аларның ир һәм (яки) кыз туганнары укый торган Оешмаларга өстенлекле кабул итү хокукына ия.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев